Республика Татарстан

Совет Менделеевского муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль районы Советы

КАРАР

КАРАР

21.11.2022 ел Менделеевск ш. №159

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы территориясендә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына ярдәм чаралары турында

Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары вазыйфаларын башкаручы К.Г.Макаровның мәгълүматын тыңлап фикер алышканнан соң, мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарга һәм аларның гаиләләре әгъзаларына Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы территориясендә ярдәм чаралары турында фикер алыштылар.

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советы **КАРАР КЫЛДЫ**:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары вазыйфаларын башкаручы К.Г. Макаровның мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарга һәм аларның гаиләләре әгъзаларына ярдәм чаралары турында мәгълүматын игътибарга алырга.

2. Мобилизацияләнүчеләрнең гаиләләренә ярдәм итү буенча район оператив штабына:

- мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган хәрби хезмәткәрләрнең гаиләләренең, шулай ук махсус хәрби операциядә ирекле катнашучыларның гаиләләренең социаль паспортларын булдыруны тәэмин итәргә.

- әлеге карарның 2 пунктының 1 өлешендә күрсәтелгән гаилә әгъзаларының сорауларын һәм ихтыяҗларын исәпкә алуны һәм реестрын булдыруны тәэмин итәргә

- башка вәкаләтле органнар белән бергәләп, мобилизацияләнгән гражданнар гаиләләрендә балигъ булмаганнарның тормыш шартларын системалы тикшереп торуны гамәлгә ашырырга;

- мобилизацияләнгән гражданнарның гаилә әгъзаларына дәүләт һәм муниципаль ярдәм чаралары турында даими рәвештә мәгълүмат-аңлату эшләре алып барырга;

3. Менделеевск муниципаль районы территориясендә урнашкан авыл җирлекләре башлыкларына, Менделеевск муниципаль районы башкарма

комитетына, оештыру-хокукый рәвешенә һәм милек рәвешләренә бәйсез рәвештә оешмалар җитәкчеләренә тәкъдим итәргә:

- системалы нигездә мобилизацияләнгән гражданнар гаиләләренә өстәмә ярдәм күрсәтергә;

- үз вакытында ярдәм күрсәтү, шул исәптән торак-көнкүреш проблемаларын хәл итү өчен, мобилизацияләнгән гражданнар гаиләләре белән шефлык урнаштырырга;

4. «Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе», «Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе», «Менделеевск муниципаль районы башкарма комитетының яшьләр һәм спорт эшләре идарәсе» муниципаль казна учреждениеләренә мобилизацияләнгән гражданнар балалары өчен түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

- ведомство буйсынуындагы учреждениеләр базасында укыту, танып белү, ял итү, спорт һәм башка чараларны даими нигездә оештыру һәм уздыру;

- Яңа ел чараларын үткәрү планын эшләү һәм тормышка ашыру, кышкы каникул чорында ял вакытын һәм мәшгульлекне оештыру.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Менделеевск муниципаль районы Советының социаль-мәдәни мәсьәләләр буенча даими комитетына йөкләргә.

Совет рәисе Р.И.Беляев